# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Салих торак пунктында

2021 елның 18 декабре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Салих авыл җирлегендә гражданнар җыены

Карар:

1. 2022 елда үзара салым акчасын Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:
- Калинин урамы буенча гравий-вак таш катнашмасы белән юлларны өлешчә ремонтлау Гагарин урамы буенча 22-нче номерлы йорт, Калинин урамы буенча 5-15-нче номерлы йорт;
- җирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда төзекләндерү һәм карап тоту.

Гражданнар җыенында рәислек итүче З. С. Галләметдинов

Салих авыл җирлеге башлыгы : З. С. Галләметдинов